






*Илең турында уйласаң,*
*Гомерең озын була.*







# Муса Җәлил

## 1906-1944

*Шагыйрь* ***Муса Җәлил****(Муса Мостафа улы Җәлилов)1906 нчы елның 15 нче февралендә Оренбург өлкәсе Мостафа авылында туа.Кечкенәдән үк китаплар укырга,музыка тыңларга,рәсемнәр ясарга ярата.Әбисе сөйләгән әкиятләрне кечкенә китапчыклар итеп тегеп, үзенең нәни "китапханә"сен дә булдыра.Муса башта авыл мәктәбендә,аннары Оренбургта "Хөсәения" мәдрәсәсендә белем ала.Ун-унбер яшьләрендә үк беренче шигырьләрен яза.*

*1922 нче елда Муса Җәлил Казандагы педагогия институтына укырга керә.1923-1925 нче елларда биредә белем ала.1925 нче елда Казанда Җәлилнең" Барабыз"дрип аталган беренче шигырьләр җыентыгы басыла.*

*Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк, шагыйрь,үзе теләп,фронтка китә.1942 нче елның июнь аенда Волхов фронтында авыр яралана,иптәшләре белән бергә фашистларга әсирлеккә эләгә.Муса Җәлил әсирлектә дә туган иленә,халкына булган мәхәббәт , ирекне сөю,фашизмга нәфрәт турында шигырьләр яза.*

*Муса Җәлилне Һәм аның көрәштәшләрен фашистлар җәзалап үтерә.Үлгәннән соң,Муса Җәлилгә Советлар Союзы герое дигән исем бирелә.*

# Муса Җәлил

## Кызыл ромашка.

- Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.
Назлады җил аларны,
Тибрәтеп ак чукларын,
Таң сипте өсләренә
Хуш исле саф чыкларын.
Чәчкәләр, кәефләнеп,
Җай гына селкенделәр.
Һәм кинәт шунда гаҗәп
Бер яңа хәл күрделәр.
Ерак түгел моңаеп,
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.
Ромашкалар бар да ак,
Аерылмый бер-береннән;

Ничек болай бер үзе
Ул кызылдан киенгән?
Әйттеләр: «Син, сеңелкәй,
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нидән кызыл чукларың?
Нидән алсу төсләрең?»
Әйтте кызыл ромашка:
— «Төнлә минем янымa
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.
Ул берүзе сугышты
Унбиш укчыга каршы;
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.
Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик охшады Чулпанга.
Егет китте, мин калдым
Канын саклап чугымда,
Көн дә аны сагынып,
Балкыйм мин таң нурында».



# Фатих Кәрим

## 1909-1945



**Фатих Кәрим** (9 гыйнвар, 1909 ел, Ает авылы, Башкортстанның Бишбүләк районы — 19 февраль, 1945 ел, Кенигсберг тирәләре) – татар шигъриятенең сәнгатьчә үсешен яңа, югары дәрәҗәгә күтәреп, гражданлык каһарманлыгы һәм шигъри батырлык күрсәтеп, милләтебезнең һәм аның сүз сәнгатенең йөз аклыгы булырлык мирас калдырып һәлак булган шагыйрь.

# ФАТИХ КӘРИМ

## Ватаным өчен.

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында,
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.





# Абдулла Алиш
## 1908-1944

**<u>Абдулла Алиш</u>** (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә Татарстан АССРның Куйбышев районы (элекке Казан губернасы Спас өязе) Көек авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

Абдулла алты-җиде яшьләрендә әтисеннән укырга-язарга өйрәнә, авылда башлангыч белем ала, ә 1917 елда әтисе аны үзләреннән 15 чакрымдагы Ямбакты мәдрәсәсенә илтә. А. Алиш аны 1919 елда тәмамлап, 1921 елга чаклы Бураково авылындагы яңа ачылган совет мәктәбендә, 1927 елга кадәр Спас (хәзерге Куйбышев) педагогия техникумы каршындагы җидееллык рус мәктәбендә укый. Шушы елларда ул әдәби иҗат өлкәсендә каләмен сыный башлый.

# Абдулла Алиш

***Саргаешып каен яфраклары***
***Өченче кат җиргә коела.***
***Өч кенә ел үтте микәнни соң?***
***Ун ел үткән кебек тоела.***

***Ил бәйрәмен инде өченче кат***
***Тоткынлыкта, читтә үткәрәм.***
***Бер файдасыз, дуслар, үтә гомер***
***Бушка үтә, үтә, әй әрәм!***

***Бүген тагын инде өченче кат***
***Килеп җитте менә ул бәйрәм,***
***Хыялымда бергә бәйрәм итәм,***
***Дуслар белән бокал күтәрәм.***

***Дүртенчесен инде насыйп булсын***
***Каршыларга мул бер табында.***
***Балаларым, иркәм белән бергә***
***Чөкердәшеп өстәл янында.***



# Адлер Тимергалин

1931-2013



**Адлер Камил улы Тимергалин** — татар язучысы, тәрҗемәче, СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1975 елдан).

Ул 1931 елның 1 гыйнварында Татарстан АССРның Сарман районы Иске Минзәләбаш авылында укытучы гаиләсендә туган. 1948 елда урта мәктәпне тәмамлый, аннары ике елга якын В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының физика-математика факультетында астрономия бүлегендә белем ала. 1952 елда ул Ташкентка китеп, андагы Укытучылар институтына укырга керә. Институтның физика-математика бүлеген тәмамлаганнан соң, 1955 елның кышына кадәр туган авылындагы җидееллык мәктәптә физика һәм математика фәннәре укыта. 1956 елда Казанга килә һәм, Пионерлар йортында фәнни-техник түгәрәк җитәкчесе булып бераз эшләгәннән соң, 1969 елларда Татарстан китап, нәшриятында фән-техника әдәбияты редакторы хезмәтен башкара. 1970—1978 елларда ул — язучы-профессионал, фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә, ә 1979 елның январеннан яңадан Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор булып эшли.



# Рәхим Саттар

## 1912-1943


**<u>Рәхим Саттар</u>** (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров) 1912 елның 15 августында хәзерге Башкортстан АССРның Чишмә районы Түбән Хаҗәт авылында крестьян гаиләсендә туа. Дүртенче класста укыганда ук инде шигырьләр яза башлый. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, башта туган ягында төрле эшләрдә йөри, аннан Казанга күчеп килеп «Кызыл яшьләр» газетасында әдәби хезмәткәр һәм җаваплы редактор урынбасары булып эшли, төрле газета-журнал битләрендә шигырьләрен бастыра.

Р. Саттар 1941 елның җөендә үзе теләп сугышка китә, десантчы булып күп кенә хәрби операцияләрдә катнаша. 1942 елның маенда чираттагы хәрби операция вакытында чолганышта калып, фашист әсирлегенә төшә. Берничә ай Смоленск, Борисов шәһәрләрендә тоткынлыкта булганнан соң, Берлин янындагы Вустрау шәһәренә озатыла. Шунда ул Абдулла Алиш белән очраша, Муса Җәлил һәм җәлилчеләрнең яшерен антифашистик оешмасы эшенә якыннан катнаша башлый. Ул әсирләр лагерендагы «Идел-Урал» легионында гитлерчыларга каршы язылган листовкалар язуда һәм таратуда катнаша. Озакламый аны бу эше өчен кулга алырга тиеш булалар, ләкин батыр сугышчы һәм шагыйрь 1943 елның июнь аенда лагерьдан кача һәм билгесез югала.

# Рәхим Саттар

## Халкым өчен.

Көнчыгышта алсуланып
Ата ал таң.
Күккә калкып таулар күренә,
Гүя калкан.
Алга карыйм. Анда ята
Томан һаман.
Ерак Туган илдә яши
Газиз анам.
Коралдашлар яу кырында!
Кайда соң мин?
Кем мин сиңа, ятиммени?
Әйт, Туган ил!
Бар хәсрәтең, бар михнәтең
Миңа уртак.
Син генә сук, син иркәлә,
Син мине как.
Ләкин син бел: һәр сулышым,
Барлык көчем
Синең өчен, Туган илем,
Синең өчен!



# Гадел Кутуй

## 1903-1945



Язучы һәм шагыйрь Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев)1903 нче елның 28 нче ноябрендә Саратов губернасының Татар Кынадысы авылында туа.1942 нче елның июнендә сугышка китә.Сугыш беткәч,1945 нче елның 15 нче июнендә Польшада вафат була. Гадел Кутуй шигырьләр, хикәяләр,повестьлар,нәсерләр язган.

# Гадел Кутуй

## Туган ил.

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта,
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың,
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар…
Рәхәт иде ул чаклар,
Бүген дәле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың,
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың…

И данлы ил, и шанлы ил,
Син минем туган илем,
Киткән чакта эчкән суың
Тәме авызда минем.

И туган ил, и матур ил,
Нур күмә калаларың,
Һәр иртә-кич сине, илем,
Сагына балаларың.

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!



